***Фәннур Сафинның тууына - 75 ел*** // Чаян. – 2023. – №6. – Б. 17.

## ФӘННУР САФИННЫҢ ТУУЫНА - 75 ЕЛ



*1948 елның 27 июнендә Татарстан Республикасының Минзәлә районы Күзкәй авылында туа. 1966 елда урта мәктәпне тәмамлагач, ул комсомол путевкасы белән Түбән Кама төзелешенә килә һәм нефть-химия комбинатында өч елга якын слесарь булып эшли. 1969-1974 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлаганнан соң, бераз вакыт Казан телестудиясендә - мөхәррир, аннары озак еллар «Татарстан яшьләре» газетасы, «Ялкын», «Казан утлары» журналлары редакцияләрендә - әдәби хезмәткәр, Татарстан Язучылар берлегенең Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре, «Мәгариф» китап нәшриятында мөхәррир вазыйфаларын башкара.*

*Фәннур Сафин матур әдәбиятка бик яшьли килеп, башлангыч мәктәптә укыганда ук беренче шигъри тәҗрибәләре белән «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында күренә башлый. Студент елларында иҗат иткән шигырьләре исә «Беренче карлыгачлар» (1970), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрә.*

*Шагыйрьнең беренче мөстәкыйль китабы - «Кеше юлга чыкса» (1976) исемле җыентыгы «Җитмешенче еллар Корчагиннары» дигән Бөтенсоюз конкурсына куелып, җиңүчеләрнең берсе итеп танылa.*

*Ф.Сафин - нигездә, лирик шагыйрь. Аның шигырьләре яшьлек романтикасы белән мул сугарылган булып, уз замандашларының күңел кичерешләре, туган җир, туган табигать турында лирик уйланулар рәвешендә кабул ителәләр. Шагыйрьнең лирикасына халыкчан тел бизәкләре, беркадәр моңсулык һәм сагыш белән өртелгән җылылык хас. Бу сыйфатлар аның «Сез кемнәр?» (1980), «Тынлык» (1982), «Күкчәчәк» (1985), «Чәчәк гомере» (1988) исемле соңгы җыентыкларына кергән поэма һәм шигырьләренең дә хис һәм кичерешләр эчтәлеген тәшкил итә.*

*Ф. Сафинның лирик шигырьләренә профессиональ һәм үзешчән композиторлар тарафыннан күп кенә җырлар иҗат ителә. Аның «Бир кулыңны», «Хушлашырга ашыкма», «Җырымда юатырмын», «Ялгыз көймә», «Мәхәббәт шатлыгы» шигырьләре көйгә салына һәм популярлык казана.*

*Ул балалар өчен дә яза. Аның балаларга атап язган шигырьләре һәм әкиятләре вафатыннан соң 1993 елда басылып чыккан «Яңгыр малае» исемле җыентыгында урын ала.*

*Фәннур Сафин 1992 елның 30 яки 31 декабрендә ялгыз яшәгән фатирында кинәт вафат була.*

*Фәннур Сафин - 1978 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ӘНКӘЙ!

*(Бер көндәлектән)*

Үз илем бар, рәхмәт, әнкәй!
Үз телем бар, рәхмәт, әнкәй!

Дөньяларда ямьнәр табып,
дулкынланып, ярсып-янып
яшәү шундый рәхәт, әнкәй, -
барысы өчен рәхмәт, әнкәй!

Ризык
биргән,
гомереннән
өзеп биргән син үк, әнкәй...
Ләкин бөтен рәхмәтләрне ничек
әйтим? - Син юк, әнкәй...

## МУЗЕЙ АЧТЫМ...

Мин гаҗәеп музей ачтым.
Анда
Фатих Кәрим язган каләм бар.
Мин өр-яңа музей ачтым.
Анда,
Кутуй кайта, дигән хәбәр бар.

Минем музеемда Мөҗәйләрдән,
Алишлардан яңа хатлар бар. Анда
Җәлил ярсып шигырь укый! Ә
янында...
аның башын кискән балта бар.
Музеемда -
канәфер чәчәкләре,
кашкарыйлар,
кыргый гөләпләр.
Ядрә тишеп үткән йөрәкләр бар,
Үтерелгән җырлар,
теләкләр...

Музеемда - каен тузы түгел - ә
кешеләр янган мичләр бар, һәм
солдатлар сөйгән хатыннарын
соңгы тапкыр кочкан кичләр
бар... Ярсу хисләр, бетмәс үчләр
бар!..

Табалмассыз ләкин ул музейны,
җитсәгез дә җирнең читенә... Яңа
музей - минем йөрәгемдә,
килегез сез аңа, Кешеләр!..



## ОНЫТМАДЫМ

Туган якның мамык карын,
Катлам-катлам болытларын -
Онытмадым!..

Күкчәчәкле болыннарын,
Балкып торган кызыл ярын -
Онытмадым!..

Никтер тагын Ык суларын,
Бөдрә-бөдрә яшел талын -
Онытмадым...

...Янә кайттым. Тауларына
менеп бактым, Ярларына
төшеп яттым, Иләсләнде
күңел. - Онытылырлык түгел
Берние дә Туган якның -
Балачакның...

## АЛМА БАКЧАСЫНДА

Туп-туп коела алмалар, "Син!" дип барсам - җил исә. Ул алманы мин үзем дә Өзәр идем югыйсә.

Өзәр идем... Һәм әйтерсең Гомер буе, бер генәм, Кычытканга чагыла-чагыла Мин алмага үреләм.

Ә ул алма йолдыздан да Югарырак икән бит! Юкка җанны ышандырам Беркөн буем җитәр дип.

Җиталмагач, өмет өзеп Күзләр түбән карады. ...Күктән эзләгәнмен икән Яныма төшкән алманы!..